Ш. Мәрҗанинең җиде томнан торган «Вафийәт әл-әсляф вә тәхият әл-әхляф» («Бабаларыбыз һәм аларның киләчәк буыннарга сәламнәре турында җентекләмә») дигән биобиблиографик сүзлеге 1837–1889 елларда язылa һәм безнең көннәргә кулъязма рәвештә килеп ирешә. Әлеге әсәрендә ул, VII–XIX гасырлар мөселман Көнчыгышының атаклы иҗтимагый-сәяси эшлеклеләре белән бергә, татар халкының күренекле вәкилләре хакында бай мәгълүмат бирә. Әлеге хезмәтнең кереш өлеше «Мөкаддимә» исеме белән 1883 елда нәшер ителә **(32–35 нче фотолар)**.

* * *

Безнең көннәргә кадәр Мәрҗанинең кулдан язылган берничә хезмәтавтографы гына килеп җиткән. Шунысы да мәгълүм: ул хезмәтләрен башта үзе язган, соңыннан аларны шәкертләре яисә махсус каллиграфлар күчерә торган булган, бу исә хәзерге вакытта безгә Мәрҗанинең беренче варианттагы хезмәтләре белән танышу мөмкинлеге бирә. Галим, хәтеренә генә ышанып бетмичә, үзенең башында туган фикерләрне шунда ук кәгазьгә төшереп барырга тырышкан. Кайчак башына бер фикер килеп, төнлә аны йокы бүлмәсенең диварына сызгалап куя да, иртән аларны кәгазьгә күчереп яза торган булган.

Мәрҗанинең тормыш юлы һәм эшчәнлегенә нисбәтле документлар – аның кайбер кулъязмалары, китаплары, фотографияләре ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас

үзәгендә саклана. (Барлыгы 28 саклау берәмлеге теркәлгән, шуларның күбесе әлеге альбомда урын алды.)

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларында Мәрҗани кулы белән язылган берничә автограф саклана. Әлеге раритетлар китапханәгә 1990 еллар уртасында, аларны, репрессияләрдән дә курыкмыйча, өй архивында саклап кала алган нәсел дәвамчылары тарафыннан тапшырыла. Ә бит ул вакыттларда Коръәннең өйдә бер нөсхәсе табылган очракта да төрмә, зинданга япканнар, совет инквизиция учагында, хәтта, гарәп графикасы белән язылган марксизм-ленинизм классикларының хезмәтләре дә янган.

ТР Милли китапханәсендә саклanучы автографлардан Шиһабетдин Мәрҗанинең 1876 елның 12 сентябрендә Казан татар укытучылар мәктәбен ачу тантанасында ясаган чыгышының караламасы аеруча игътибарга лаек. Әлеге мәктәп танылган тюрколог галим, Казан белем бирү округының татар мәктәпләре инспекторы Василий Радлов (1837–1918) тырышлыгы белән ачыла. Казан укытучылар мәктәбенә рус-татар училищеларын һәм мәдрәсәләр каршындагы рус сыйныфларын тәмамлаган иратларны кабул иткәннәр, уку дүрт елга сузылган. Студентлар дәүләт хисабына махсус кием, торак һәм азык-төлек белән тәэмин ителгәннәр. Төп предметлар булып рус теле, педагогика, дидактика һәм табигать фәннәре саналган. Әлеге уку йортында Гаяз Исхакый, Мирсәет Солтан-Галиев, Гафур Коләхмәтов, Хөсәен Ямашев кебек танылган әдипләр белем алган.

Мөселман исламият фәннәре татар телендә укытылган. Дини тәгълиматны укытуны Радлов үзе белән дустанә мөнәсәбәттәге Мәрҗанигә тәкъдим итә. Ул Мәрҗани укыта башлау белән татар җәмәгатьчелеге каршында мәктәпнең дәрәҗәсе күтәрелер дип саный, әмма киресенчә килеп чыга. Кадимче муллалар Мәрҗанине «миссионер агенты» дип, аның абруен какшаталар. Шулай да Казан мәктәбендә ул тугыз ел эшли. Шул ук вакытта «немец агенты» дип игълан ителгән Радловны да читтә калдырмыйлар. Казан миссионерлары, бигрәк тә Евфимий Малов, аны татарларга аеруча яхшы мөгамәләдә булуы өчен тәнкыйтьләп чыга.

Мәрҗани Казан татар укытучылар мәктәбен ачу тантанасында ясаган чыгышында уку йортының татар халкын аң-белемле итүдәге зур әһәмиятен билгеләп уза һәм анда белем бирү ислам кануннарына каршы килмәс дип белдерә. «[...] Шәригать буенча белем һәм мәгърифәтлелек иң югары дәрәҗәдәге әхлаклылык булып санала. Башка диннәр белән чагыштырганда, ислам фәннәренең әһәмиятенә зур игътибар итә. Коръән аятьләрендә һәм Мөхәммәд пәйгамбәребезнең хәдисләрендә гыйлем өйрәнүгә өндәүләрне санап бетерерлек түгел. Әлеге мәктәпне ачу өчен үзенең югары карары, матди ярдәме һәм рәхимле-

лege белән Бөек Русия императорының мөселманнар хакында онытмавын, аларның үсеше һәм белеме турында уйлануын, аның кул астында яшәүче мөселманнарның иминлеген кайгыртуын күрәбез.

Аллаһка шөкер, аның мәрхәмәте һәм тырышлыгы белән без яхшы тәэмин ителгән шушы мәктәпне ачабыз. Без, мөселманнар, аңа рәхмәт сүзләре яудырырга, аның рәхимлелеген олыларга тиешбез [...].

Белемгә омтылучы барча кешеләр, үзегезнең билгеләнгән вакытыгызны заяга уздырмагыз, фәннәр өйрәнүгә, камиллеккә омтылырга тырышыгыз, чөнки бары гыйлем аркылы гына без яшәгән җәмгыять тагын да әхлаклы һәм гадел була ала [...]» **(36–43 нче фотолар)**.

Казанда 1864 елда Мәрҗанинең Урта Азия төрки халыклары тарихына багышланган беренче хезмәте – «Гыйрфәтел-хәвакыйн ли-ирфәт әл-хәвакыйн» («Ханнарның тораклары һәм аларның тормышларын өйрәнү») исемле әсәре басылып чыга. Бу хезмәттә Чыңгыз хан яуларына кадәр ике йөз ел алдан Мавәраэннәһер җирләрендә яшәгән төрки кабиләләрнең үзара мөнәсәбәте, алар арасындагы идарәчелек өчен көрәш кебек катлаулы мәсьәләләр үзәккә алына. Мәрҗанинең әлеге китабына кадәр Урта Азия тарихына нисбәтле бу дәвер хакында фәкать өзек-өзек мәгълүматлар биргән төрек галиме Мөнәҗҗим-башының «Сәхаифел-әхбар» («Хәбәрләр сәхифәсе») исемле хезмәте генә була. Аны Европа галимнәре еш файдалана. Мәрҗанинең бу әсәре, В.В. Бартольдның «Монголлар явы чорында Төркестан», «Җидесу тарихы буенча очерк» хезмәтләре басылганчы, әлеге мәсьәләгә багышланган төп һәм ышанычлы чыганак булып тора. Ул бүген дә уйгыр һәм караханидлар династиясе турында чагыштырмача тулы мәгълүмат биргән тарихи хезмәтләрдән санала.

Мәрҗани 1876 елда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп сайлана. Татар галимнәреннән беренче булып, Археологларның IV корылтаенда Болгар һәм Казан тарихы турында доклады белән катнаша. Бу чыгыш Радлов тәрҗемәсендә «Завеса времени, покрывающая историю Болгара и Казани» («Гыйләлатез-заман фи тарих Болгар вә Казан») исеме белән Россия археологларының IV корылтае материаллары җыентыгында басылып чыга.

В. Радлов Мәрҗанинең Алтын Урда ханнары тарафыннан сөйләнгән тәхет нотыкларын һәм теге яки бу ханга багышланган дини китапларның кереш сүзләрендәге кыйммәтле мәгълүматларны туплавын югары бәяли. Н.П. Загоскин, Н.И. Ашмарин, М.Г. Худяков һ.б. күренекле галимнәр аның әлеге хезмәтеннән еш файдаланалар. Соңыннан «Гыйрфәтел-хәвакыйн ли-ирфәт әл-хәвакыйн»га кергән күп кенә мәгълүматлар Мәрҗанинең иң зур тарихи басмасы саналган ике томлы «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә

Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») хезмәтендә дә урын ала. Әлеге әсәр төрле чыганаклардан файдаланып язылган һәм ул, һичшиксез, халкыбызның тарихи үткәнен яктырткан, татар телендә язылган беренче тулы тарихи хезмәт буларак санала **(44–45 нче фотолар)**.

Мәрҗани гомер буена үзенең яраткан укучысы, XIX гасырның мәшһүр галиме Хөсәен Фәезханов (1823–1866) белән аралашып, хат алышып яши. Фәезханов остазын үз чорындагы мөселман галимнәреннән бер башка өстен куя, аңа фәнни мәсьәләләрдә киңәш сорап мөрәҗәгать итә, үз гыйльми табышлары һәм ачышлары белән уртаклаша, аның авыр чорларында ярдәм итә, җыеп әйткәндә, Мәрҗани өчен Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре арасында арадашчы ролен үти.

Мәрҗани һәм Фәезханов арасындагы хатлар бу шәхесләрнең иҗат лабораториясен бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән аңларга ярдәм итә. Хатларда без бу могтәбәр затларның чыганаклар һәм дәлилле фактларга таянып эш итүләрен, нинди китап һәм автор хезмәтләреннән файдалануларын күрәбез. Бу исә, Мәрҗани һәм Фәезхановларның фәнни яктан нигезле эш йөртүләре, җитди чыганакларга таянулары хакында сөйли.

«Сез үзегезнең “Тарих”ыгызны тәмамладыгызмы әле? – дип сорый Фәезханов үзенең остазыннан, – Мин сездән болгар ханнары хакында мәгълүматларны барлап миңа җибәрүегезне сорасам, сезне бик борчымаммы? Минем өчен аларның биографияләре, яшәү һәм үлгән еллары, аларның гаиләләре турында мәгълүмат кызыклы. Шулай ук, чынгызилар һәм тимурилар хакындагы хәбәрләрне дә әзерләсәгез иде. Алар турында һәр мәгълүмат – туган һәм үлгән еллары, әмирлек итү еллары – кызыклы булыр иде. Бу хәбәрләр, тарихи чыганаклар белән дәлилләнсә, тагын да яхшырак булыр иде [...]. Сезнең “Тарих”ны язып тәмамлау, һичшиксез, күп хезмәт сорый торган эш. Иншалла, барысы да бик яхшы булыр [...]» **(46–47 нче фотолар)**.

Мәрҗанинең фәнни хезмәтләре Казан университетының В. Радлов, И.Ф. Готвальд, А.К. Казембәк **(48–49 нчы фотолар)** кебек танылган галимнәре тарафыннан югары бәяләнә. Алар Ш. Мәрҗани белән тыгыз элемтәдә торалар, еш кына аның Захарьевский (хәзерге Каюм Насыйри) урамында урнашкан өенә дә киләләр. Шунысы да игътибарга лаек, Мәрҗани үз өендә башка танылган кешеләрне дә кабул итә. Мәсәлән, 1873 елда – Кашгар илчесе, 1876 елда мәшһүр немец галиме, «Хайваннар тормышы» китабы авторы Брем, Көнбатыш Себергә барышлый, Мәрҗанидә кунак булалар. Соңгысы Мәрҗанине үзенең гарәп телен бик яхшы белүе белән таң калдыра һәм, алар үзара нәтиҗәле аралашып, эчтәлекле әңгәмә коралар **(50 нче фото)**.

* * *

Мәрҗани хәлле һәм бай кеше саналган, бу исә аңа башкалардан бәйсез тормыш белән яшәргә мөмкинлек биргән. Ул кемнәрдәндер баш иеп ярдәм сорауны яратмаган, күбесенчә үз көче һәм хәләл малы хисабына яшәгән. Бервакыт, ул үзенең кичектергесез эшләре белән туган авылына кайтып килергә уйлый. Моның өчен аңа фәкать байларда гына була һәм сирәк файдаланыла торган зур йөк чанасы кирәк була. Аның танышлары: «Әнә фәлән сәүдәгәргә барып чанасын сорап тор», – дип киңәш бирәләр. Әмма Мәрҗани үзенчә эшли: байга түгел, базарга китә, һәм барлык акчасына йөк чанасы сатып ала.

Ул бик затлы киенә, иң яхшы һәм токымлы атларны җиктерә. Шулай ук, иске китаплар, кулъязмалар, антиквариат сатып алуга акчасын кызганмый, үзен мирасның кадерен белүче буларак та таныта.

Бервакыт Корбан бәйрәменә мәчеткә Мәрҗани зиннәтле тун киеп килә. Имеш-мимешләргә караганда, бу тунның бәясе 500 сум (ул чор өчен бу бик зур акчалар санала) тора. Барлык кеше гаҗәпкә кала, чөнки иң бай дип саналган кешеләрнең дә андый кыйммәтле туннары булмый. Шуңа да галимне тәкәбберлектә гаепиләр. Ул: «Эх, сез, наданнар! Байлар 200 сумлык тун кигәндә, галим кешегә аның 500 сумлыгы кирәклеген аңламыйсызмы? Әгәр кеше 300 сумлык ат җиксә, гыйлем иясенә 500 сумлык ат табарга кирәк. Юкса, халык арасында галим-голяманың абруе булмас», – дип белдерә **(51–52 нче фотолар**.

Ул бер үк вакытта ике алтын сәгать йөрткән. Шәкертләре исә шаяртып, аннан вакытның күпме булуын сорый торган булалар. Остазлары: «Вакыт сораганчы, китап укыгыз, аларда барлык сорауларга җавап табарсыз», – дип, җаваптан кача торган була.

Мәрҗани үзенең барлык вакытын фән һәм дингә багышлый. Үз алдына нинди дә булса максат куя икән, аңа ирешмичә туктамый. Бервакыт, бер ай дәвамында Коръәнне тулысынча укып чыгарга карар кыла. Мәрҗани сүрәләрне намаз вакытларында гына түгел, мәчет яисә мәдрәсә юлында да кабатлап барган. Әгәр дә аять озын булып, юлы дәвамында гына тәмамланмаса, ул, аны кабатлап бетергәнче, күрше урамнардан да урап бара торган була. Күңеленнән кабатлап йөргәндә ул, әйләнә-тирәдәгеләргә күзе төшеп, зиһене чуалмасын өчен, аяк астына карап йөргән имеш. Юлда очраучылар: «Безнең муллабыз бик масайган, сәламгә дә җавап кайтармый», – дия торган булганнар. Алар Мәрҗанинең үз уйлары белән мәшгульлеген, аның өчен фән һәм белем беренче урында булуын сизмәгәннәр әлбәттә. Гадәттә ул үзен урам уртасында туктатуларын өнәп бетермәгән, очрашуларны мәчет каршында яисә үз йортында билгеләгән. Шиһабетдин хәзрәтнең уй-хыялларына күмелеп йөрүенә

берни дә комачаулый алмаган, ул бары урам этләреннән нык курыккан һәм алардан саклану өчен үзе белән таяк йөрткән.

Шуны да әйтергә кирәк, «уйларыннан айнып киткән» вакытларында үзенә игътибар итүне бик яраткан. Үзенең шәкертләренең туктап, барлык таләпләр буенча сәлам бирүләрен аеруча хуп күргән. Кайбер шәкертләр Мәрҗанине күрүгә, урамның икенче ягына йөгереп чыгалар икән – бу сәер мөдәрриснең башында ни булганын кем белсен. Әмма галим андый очракта аларны каты тиргәгән, үгет-нәсыйхәт укыган.

Мәрҗани Россия, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре буйлап күп сәяхәт итә, 1880 елда ул һәр мөселман кешесе өчен фарыз саналган хаҗ сәфәре кыла.

XIX гасырда изге җирләргә гыйбадәт кылу иң көчле һәм чыдам кешеләр көченнән генә килә. Күренекле татар эшлеклеләренең күпмесе хаҗ сәфәре юлында ятып калган. Әйтик, шагыйрь Аллаһияр Суфи 1713 елда Искәндәриядә вафат була, дин белгече Габденнасыйр Курсави 1812 елда хаҗ сәфәре вакытында Истанбулда чума авыруыннан үлеп китә.

Яхшы юлларның булмавына, күп төрле куркынычлар янавына карамастан, безнең ата-бабаларыбыз озын юлга кузгалганнар, сәфәр берничә ай дәвамында җәяүләп, ат, дөяләрдә, иң кулае су юлы белән башкарылган.

Шушы катлаулы һәм ураулы хаҗ сәфәрен безнең Мәрҗани дә уза. Казан шәһәрендә ул Вольский корабына утырып, Түбән Новгородка кадәр бара, аннан поезд белән Мәскәү һәм Киев аркылы Одессага барып җитә. Соңыннан пароходка утырып Истанбулга килә. Аннан Мисырның Искәндәрия шәһәренә янә пароход белән бара. Мисырны поезд белән кичеп – Сүәешкә, янә пароходка утырып Гарәбстанга барып ирешә **(53–56 нчы фотолар)**.

Мәрҗани мөселман дөньясында ислам дине һәм дөньяви фәннәр белгече буларак дан казана. Ул гарәп телендә яза, шунлыктан Көнчыгыш Гарәбстанда да яхшы танылa. Казанда ул иң яхшы Коръән белгече булып санала, шул сәбәпле 1860 елда Диния нәзарәте аңа басылып чыккан Коръәннәрнең төгәллеген тикшерү вазифасын йөкли. Бу эшкә ул күп вакытын һәм көчен сарыф итә **(57 нче фото)**.

Мәрҗани белән күренекле татар галиме Хөсән Фәезханов арасында йөргән хатлар сакланган. 1860 елда язылган хатында Фәезханов аңа: «Коръәннән кала башка китапларны төзәтү һәм тәгаенләү бик катлаулы һәм күп көч сарыф итә. Дүрт-биш тапкыр укып, һәрбер нечкәлегенә төшенеп утырсаң да, барлык хаталарны төзәтеп бетереп булмый. Әлбәттә, белемле бер шәкертегез яхшы басылган оттиск укып, берничә кат чагыштырып чыкса, әйбәт булыр иде. Үзегез шуннан соң гына текстны берничә тапкыр карасагыз иде», – дип яза.

Әмма Мәрҗани барлык эшне үзе башкара. Үзенең хаталары яисә каралып

җитмәгән өлешләре калса, әлеге Коръәнне үз хисабына яңадан бастыра торган була.

Шулай да, ничек кенә тырышмасын, аны «яратып бетермәүчеләр» дә табыла. Алар аның вак кына җитешсезлекләрен күреп, тикшерүче оешмаларга хәбәр итәләр. Шуның нәтиҗәсендә Казан галиме әлеге эшеннән азат ителә.

Шиһабетдин Мәрҗани бик пөхтә кеше була, үз архивына түләү квитанциясе кебек әһәмияте аз булган кәгазьләрне дә җыеп, туплап бара. Ул шапшаклыкны яратмый, һәрвакыт чиста, пөхтә киенеп йөри. Мәрҗанинең эш көне төн урталарына кадәр сузыла.

Галим вакытны заяга уздырырга теләми. Вак-төяккә игътибар итәргә туры килгәндә чыгырыннан чыга. Мәсәлән, ишекләрне элмә йозак белән бикләүне, бигрәк тә аны (йозакка яңгыр суы кертмәү максатыннан) өскә күтәрткәнне яратмый. «Карагыз, күпме вакыт заяга уза: башта йозакны төшерәсең, соңыннан ачкычны урнаштырасың, ачасың – ишекне бер кул белән генә дә ачып була бит», – дип сукрана торган була. Бәлки бу Мәрҗанинең барлык гамәлләрен дә гел уң кулы яисә аягы белән башкаруыннан килеп чыгадыр. Аңа ат арбасына утырганда яки атка атланганда, сул аякны катнаштырмыйча, уң аяк белән менү өчен бик тырышырга кирәк була. Шулай ук әңгәмәдәше янында да ул һәрвакыт уң ягы белән утырган.

Мәрҗани тәкъва һәм дини кеше була, һәр намазны мәчеттә укырга тырыша. Аның яшьлегендә Урта Азиянең дин әһеле әл-Букалиның төнге ястү намазын безнең киңлектә, караңгылык төшмәгәнлектән, үтәү мәҗбүри түгел дигән фикер хөкем сөрә. Әлеге намазны Казан имамнары, Мәрҗанинең әтисе һәм Шиһабетдин үзе дә укымый торган булалар. Белемнәре тирәнәя барган саен, ул үзенең зур хата кылуын аңлый бара. Шунлыктан, барлык укылмый калган, авырганда калдырылган намазларын ул өстәмә башкара.

Хезмәтләрен гарәп, фарсы телләрендә язса да, Мәрҗани үзенең туган теленә ихтирамын югалтмый. Кайбер шәкертләренең, модага ияреп, «яңа телдә», рус сүзләрен кушып сөйләшкәнен ишетсә, бик каты орыша, «тел бетү – милләт һәм дин бетүдер», – дип әйтә торган була.

* * *

Мәрҗани өч мәртәбә өйләнә, әмма аның өчен гаилә тормышы икенче планда була. Яшьлегеннән үк җаны-тәне белән фән дөньясына бирелә, аңа барлык көчен һәм вакытын сарыф итә. Аның үзеннән соң ике хатыны, ике кызы һәм бер улы кала. Бердәнбер варисы дип саналган улына ул күп өметләр баглый. Аны Истанбул мәдрәсәсендә укытып, мулла һәм мөддәрис итә, әмма улы, психик авыруга дучар булып, эшеннән китә.

Гомерен киеренке хезмәттә уздыру, өлкән яшькә җитү Мәрҗанинең көч-куәтен киметә. Соңгы елларында галим каты авы-

рый. Ашказаны авыртудан, ашый алмыйча, нык ябыга, хәлсезләнә. Үлем түшәгендә ятканда да галим фән турында кайгырта. Ул үзенең татар һәм төрки халыкларының тарихына багышланган «Мөстәфаделәхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтен тәмамлап калдырырга тели.

Күпсанлы җитди чыганакларга нигезләнеп язылган әлеге әсәр татар тарихы буенча беренче гыйльми хезмәт санала. Мәрҗани анда татарларның дәүләтчелекләрен саклап кала алмау сәбәпләре хакында фикер йөртә. Ул Идел Буе Болгар дәүләтенең таркалуын, монгол яуларыннан булмыйча, ил эчендә барган низаглардан күрә.

Әлеге трактатны язганда Шиһабетдин Мәрҗани Ибне Рөстә, Ибне Хәукаль (X гасыр), Әбү Ногайм, әл-Бәкри (X–XI гасырлар), Идриси, Әбү Хәмид әл-Гарнати, Зәкәрия Казвини (XII—XIII гасырлар), Ибне Халдун, Ибне Баттута (XIII–XIV гасырлар) кебек абруйлы әдипләрнең хезмәтләреннән файдалана. Билгеле булганча, галим, шулай ук, рус елъязмаларын һәм китапларын да (мәсәлән, «Борынгы заманнар елъязмасы» («Повесть временных лет»), Шәрык белгече Д.А. Хвольсон хезмәтләрен) куллана. Шулай ук, борынгы татар легендариваятьләрен чын фәнни чыганак буларак кабул итеп, аларны да игътибарыннан читтә калдырмый.

Китабының соңгы өлешләрен автор шәкертләренә әйтеп яздыра һәм, үзе үлеп киткән очракта, алардан үз өслүбенә таянып, әсәрен тәмамлауларын сорый.

Мәрҗани 1889 елның 18 апрелендә бакыйлыкка күчә, соңгы сүзләре «Лә иләһә илләллаһ» була **(58 нче фото)**.

Ш. Мәрҗани эшчәнлегенә багышлап Казанда уздырылган бер конференциядәге чыгышында тумышы белән сүрияле галим Тәүфикъ Ибраһим мондый сүзләр әйтә: «Мин үз докладымны гарәп телендә укый алган булыр идем, әмма мондый тыйнаксызлыкка бара алмыйм. Чөнки монда бу телне миннән яхшырак белгән Мәрҗани рухы бар». Танылган кунак тарафыннан әйтелгән бу сүзләр татарларның мәшһүр руханиен тирән ихтирам итү булып яңгырады **(59–76 нчы фотолар)**.

...Кечкенә шаян малай, үсеп, әнә шундый зур дәрәҗәләргә ирешә. Татар исламиятенең абруен югары күтәрүче әлеге олы галимнең исеме татар халкы күңеленә мәңгелеккә сеңгән. Аның даһилыгы бәхәсләргә урын калдырмый.

The book "Mardzhani and his era in photographs" offered to the reader opens a new page in the study of the life and scientific activities of a major Tatar scholar and theologian, historian Shihabuddin Mardzhani (1818–1889). He lived a long, very bright and eventful life: he served as imam of the First Cathedral Mosque, was a mukhtasib of Kazan, a member of the Society of Archeology, History and Ethnography at Kazan University, wrote over 30 volumes of fundamental works devoted to various issues of Muslim theology, history of Tatar people.

Sh. Mardzhani came from a family of hereditary Imams. He received a fundamental religious education in the famous madrassas of Bukhara and Samarkand, took lessons from reputable theologians, and worked independently in libraries.

In 1850, Mardzhani returned to his homeland and since then his whole life has been connected with his native land. In the same year he was appointed as imam of the First Cathedral Mosque (now the Al-Mardzhani Mosque in Kazan). In 1862, the candidacy of Mardzhani was nominated for the post of mufti - the head of the Orenburg Mohammedan Spiritual Assembly, but did not receive the support of the Chief Prosecutor of the Most Holy Synod, K.P. Pobedonostsev. In 1867–68, he was the akhun and mukhtasib of Kazan, later in 1876–1884, he taught Islamic sciences in the Kazan Tatar teacher's school.

It was during these years that Mardzhani seemed to have a second wind. He was inspired by the creative passion, the desire to say a new word in theological science, and the knowledge accumulated over the many years of study finally began to transfer, according to the laws of physics, from quantity to quality.

During this period he wrote the most significant works:

"Nazurat al-haqq fi fardiyyat al-gashai wa in lam yagib al-shafak" ("A look at the truth about the need for evening prayer regardless of the twilight", 1870), which caused a great resonance and brought fame to the author throughout the Muslim East;

"Al-hikmat al-baliga-l-juniya fi-sh-sharkhi al-gakaid al-hanafiya" ("Extremely mature wisdom in the interpretation of Hanafi dogmas", 1888), where he expounded his views on various theological and legal issues.

In general, the scientist developed various innovative religious, reforming and educational ideas in his theological writings.

Since 1860, Sh. Mardzhani was responsible for the completeness and accuracy of the text of the Kazan editions of the Koran. This experience later became the basis of his book "Al-Fawaid Al-Muhimma" ("Useful and Important", 1878), devoted to the history of the publication of the Koran in Russia.

Sh. Mardzhani's seven-volume bio-bibliographical work "Vafiyat al-Aslaf wa Takhiyat al-Akhlaf" (Introduction to the work "Details on predecessors, their greetings to descendants") was compiled by him in 1838–1889 and preserved as a manuscript. He gave detailed information about prominent social and political figures, representatives of science and culture of the Muslim East and the Tatar people of the VII–XIXth centuries in this work. In 1883, an introduction to the work was published under the title "Mukaddima kitab vafiyat al-aslaf wa takhiyat al-ahlaf".

Mardzhani left his mark in the history with his work "Mustafad al-Akhbar fi Akhvali Kazan wa Bulgar" ("Applied data on the history of Kazan and Bulgar", 1885–1900), which was devoted to the history of Bulgar, Khazar, Tatar and other Turkic peoples. This comprehensive treatise became the first work based on numerous, time-tested sources in the Tatar historical science.

Mardzhani died on April 18, 1889 at the age of 74, buried in Kazan.



**1. Портрет Ш. Марджани. 1860–70-е гг. XIX в. Фотографическое заведение прусского подданного Г.Ф. Локке (г. Казань, ул. Воскресенская, дом Алкина)**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22. Оп. 1. Ед. хр. 5*

**1. Ш. Мәрҗани портреты. 1860–70 еллар, XIX гасыр. Пруссия гражданы Г.Ф. Локкеның фотография ширкәте (Казан шәһәре, Воскресенская урамы, Алкин йорты)**

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 22. Тасв. 1. С. б. 5*



**2. Вид на родное село Ш. Марджани – Ябынчи (Епанчино) Атнинского р-на РТ. Современный вид**

**2. Ш. Мәрҗанинең туган авылы – Татарстан Республикасы Әтнә районы Ябынчы (Япанчы авылы). Хәзерге күренеше**

*https://www.business-gazeta.ru*



**3. Место дома, где родился Ш. Марджани (с. Ябынчи Атнинского р-на РТ)**

*Из фондов Арского историко-этнографического музея «Казан арты»*

**3. Ш. Мәрҗани туган йортның нигезе (Татарстан Республикасы Әтнә районы Япанчы авылы)**

*«Казан арты» Арча тарих-этнография музее фондларыннан*





**4. «Внутренность татарского дома». 1862 г. Художник К.Ф. Гун**

**4. «Татар өенең эчке күренеше». 1862 ел. Рәссамы К.Ф. Гун**

*Этнография Казанского Поволжья. Историко-этнографические очерки. Казань, 2017. С. 20*

**5. «Татарский двор». 1862 г. Художник К.Ф. Гун.**

**5. «Татар йортының ишек алды». 1862 ел. Рәссамы К.Ф. Гун**

*Карл Федорович Гун. 1830–1877. Рига, 1955*



6. Медресе в Бухаре. Фотограф С.М. Прокудин-Горский (г. Бухара. Нач. XX в.).

6. Бохара мәдрәсәсе. С.М. Прокудин-Горский фотосы (Бохара, XX гасыр башы).

*http://prokudin-gorskiy.ru*



7. Медресе «Чор-Минор», где Марджани жил в годы учёбы в Бухаре. Фотограф Я. Босин. 1958 г.

7. Бохарада уку дәверендә Ш. Мәрҗани яшәгән «Чор Минор» мәдрәсәсе. Я. Босин фотосы, 1958 ел

*https://oldcolor.livejournal.com/393652.html*



8. Улица в Бухаре с видом на медресе «Чор-Минор». Фотограф С.М. Прокудин-Горский (г. Бухара. 1911 г.)

8. Бохара шәһәрендә «Чор-Минор» мәдрәсәсе урнашкан урам күренеше. С.М. Прокудин-Горский фотосы (Бохара, 1911 ел)

*http://prokudin-gorskiy.ru*



**9. Ханака Надир-Диван-Беги. Фотограф С.М. Прокудин-Горский (г. Бухара. Нач. XX в.)**

**9. Надир Диванбәк ханәкәсе. С.М. Прокудин-Горский фотосы (Бохара, XX гасыр башы)**

*http://prokudin-gorskiy.ru*



**10. Шакирды сарты. Фотограф С.М. Прокудин-Горский (г. Самарканд, нач. XX в.)**

**10. Сарт шәкертләре. С.М. Прокудин-Горский фотосы (Сәмәрканд шәһәре, XX гасыр башы)**

*http://prokudin-gorskiy.ru*



**11. Мечеть Калян (г. Бухара, XVI в.). Современный вид**

*Фотограф З. Габдуллин*

**11. Бохара шәһәренең Калән мәчете (XVI гасыр). Хәзерге күренеше**

*З. Габдуллин фотосы.*



12. Шакирды с мударрисом. Фотограф С.М. Прокудин-Горский (г. Самарканд, нач. XX в.)
12. Мөдәррис һәм шәкертләр. С.М. Прокудин-Горский фотосы (Сәмәрканд шәһәре, XX гасыр башы)
*http://prokudin-gorskiy.ru*



13. Шакирды медресе. Фотограф С.М. Прокудин-Горский (г. Самарканд, нач. XX в.)
13. Мәдрәсә шәкертләре. С.М. Прокудин-Горский фотосы (Сәмәрканд шәһәре, XX гасыр башы)
*http://prokudin-gorskiy.ru*



14. «Медресе Шир-Дор на площади Регистан в Самарканде».
Художник В.В. Верещагин (1869–1870)
14. «Сәмәркандның Регистан мәйданында урнашкан Ширдар мәдрәсәсе».
Рәссамы В.В. Верещагин (1869–1870)



**15. Узбеки и сарты. XIX в.**

**15. Үзбәкләр һәм сартлар. XIX гасыр**

*Народы России: живописный альбом. СПб., 1878–1880 (Вып. 7–8: Камчадалы. Чукчи. Коряки. Курильцы или айносы. Амурские тунгузы. Узбеки Таджики. 1880)*



**16. Бухарец. Хивинец. Татарин. XIX в.**

**16. Бохарада, Хивада яшәүчеләр, татар кешесе. XIX гасыр**

*Description ethnographique des peoples de la Russie / Par T. de Pauly. СПб., 1862*



**17. Медресе «Мир Араб» (XVI в.), г. Бухара. Современный вид**

**17. «Мир Араб»мәдрәсәсе (XVI гасыр), Бохара шәһәре. Хәзерге күренеше**

*https://foto-tours.ru/*



**18. Казанский Кремль. XIX в.**

**18. Казан Кремле. XIX гасыр**

*Народы России: живописный альбом. СПб., 1878–1880 (Вып. 3: Молдаване. Цыгане. Татары волжские и сибирские. Татары крымские. 1878)*



**19. «Татарская мечеть». Художник Э. Турнерелли (1839)**

**19. «Татар мәчете». Рәссамы Турнерелли Э. (1839)**

*Собрание видов г. Казани, рисованных с натуры. Репринт. Казань, 1994*



**20. Вид на Сенную улицу и Соборную мечеть. Казань, нач. XX в.**

**20. Печән базары урамы һәм Җамигъ мәчет күренеше. Казан. XX гасыр башы**

*Малашевский Г.А. Старая Казань. Фотопортрет. Книга-альбом. Казань, 2005*



**21. Вид на 7-ю Соборную («Сенную») мечеть. Казань, кон. XIX в.**

**21. Җиденче җамигъ («Печән базары») мәчет күренеше. Казан, XIX гасыр азагы**

*Малашевский Г.А. Старая Казань. Фотопортрет. Книга-альбом. Казань, 2005*



**22. Сибирские и волжские татары. XIX в.**

**22. Себер һәм Идел буе татарлары. XIX гасыр**

*Народы России: живописный альбом. СПб., 1878–1880 (Вып. 3: Молдаване. Цыгане. Татары волжские и сибирские. Татары крымские. 1878)*



**23. Казанские татары. XIX в.**

**23. Казан татарлары. XIX гасыр**

*Description ethnographique des peoples de la Russie / Par T. de Pauly. СПб., 1862*



**24. Казанский татарин. Татарка казанская сзади, нач. XIX в.**

**24. Казан татары һәм Казан татар хатын-кызы. XIX гасыр башы**

*Abbildung und Beschreibung der Voelkerstämme und Voelker unter des Russischen Kaisers Alexander, Friedrich Ferdinand Hempel und Geissler. Leipzig, 1803*



**25. Вид Первой соборной мечети г. Казани (ныне мечеть «Марджани»), нач. XX в.**

**25. Казан шәһәренең Беренче җамигъ мәчете күренеше (хәзерге «Мәрҗани» мәчете), XX гасыр башы**

*«Россия Империясе» фотоальбомы (1911)*



**26. Дом, в котором жил Шигабутдин Марджани (ныне ул. К. Насыри, 10). Фото 1900–1910 гг.**

**26. Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән йорт (хәзерге Каюм Насыйри урамы, 10). 1900–1910 еллар фотосы**

*https://pastvu.com*



**27. Шагиахмет Алкин (Алексей Михайлович). Первый казанский полицмейстер из татар-мусульман (его сын стал депутатом I Государственной Думы, внук – председателем «Военного Шуро»)**

**27. Шаһиәхмәт Алкин (Алексей Михайлович). Татар-мөселманнары арасыннан Казанның беренче полицмейстере (аның улы – I Дәүләт Думасы депутаты, оныгы – «Хәрби Шура» рәисе).**

*https://www.tataroved.ru*



**28. Здание медресе, в котором с 1880 по 1889 гг. преподавал Ш. Марджани. Ныне Казанский исламский колледж (ул. З. Султана, 6/15)**

**28. Ш. Мәрҗани 1880–1889 елларда мөгаллимлек иткән мәдрәсә бинасы. Хәзерге Казан ислам көллияте (З. Солтан урамы, 6/15)**



**Это же здание в 1949 г. Фотограф Г.В. Юсупов**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22.Оп. 1. Ед. хр. 6*

**Шул ук бина 1949 елда. Йосыпов Һ.В. фотосы.**

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем.Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 22. Тасв. 1. С.б. 6*



**29. Ш. Марджани в возрасте 45 лет. Фоторепродукция**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22. Оп. 1. Ед. хр. 5*

**29. 45 яшьлек Ш. Мәрҗани Фоторепродукция**

*ТТР ФА Г. Ибраһимов исем.Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 22. Тасв. 1. С.б. 5*




**30. Татарское духовенство. Почтовая открытка конца XIX в.**

**30. Татар руханилары. Почта открыткасы, XIX гасыр ахыры**

*https://pastvu.com*



№ 1

Метрическая Книга

Въ городѣ Казани

Въ Старотатарской Слободѣ

въ Старокаменной Мечети

на 1876 годъ



**31. Метрическая книга Старо-каменной мечети г. Казани за 1876 г.
Метрическую книгу заполнял указной имам Ш. Марджани**

**31. Казан шәһәренең Иске-Таш мәчетенең 1876 елгы метрик кенәгәсе.
Метрик кенәгә указлы мулла Ш. Мәрҗани кулы белән тутырылган**

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*





**32. Книга «Назурат ал-хакк» («Китаб назурат аль хакк фи фардият ал-аша ва ин лям ягиб аш-шафак» – «Взгляд на истину о необходимости вечерней молитвы независимо от наступления сумерек», 1870)**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22. Оп. 1. Ед. хр. 28*

**32. «Нәзурател-хакк фи фәрдийә әл-гашаи вә ин ләм йагаб-әш-шәфәкъ» («Эңгер-меңгер төшүгә бәйсез рәвештә кичке намазның зарурлыгы турындагы хакыйкатькә бер караш», 1870) хезмәте**

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем.Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 22. Тасв. 1. С.б. 28*



**33. Биобиблиографический труд Ш. Марджани «Вафийат ал-аслаф ва тахият ал-ахлаф» («Подробное о предшественниках, их приветствия потомкам») (1838–1889 гг.)**

*НБ КФУ. Выставка «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.). Фотограф А.М. Ахунов*

**33. Мәрҗанинең «Вафийәт әл-әсляф вә тәхият әл-әхляф» («Бабаларыбыз һәм аларның киләчәк буыннарга сәламнәре турында җентекләмә») дигән биобиблиографик сүзлеге (1837–1889 еллар)**

*КФУ фәнни китапханәсе. «Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсе (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел). А.М. Ахунов фотосы*







**34. Печать Марджани. 1864–1865 гг.**
**Из фондов Национального музея РТ**

*Фото А.М. Ахунова с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.)*

**34. Мәрҗани мөһере. 1864–1865 еллар. Татарстан Республикасының Милли музее фондларыннан**

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсе (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел). А.М. Ахунов фотосы*

**35. Оттиск личной печати Ш. Марджани на сборнике хадисов «Сахих ал-Бухари»**

*Фото А.М. Ахунова с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.)*

**35. «Сахих әл-Бохари» хәдисләр җыентыгында Ш. Мәрҗанинең шәхси мөһере эзе**

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсе (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел). А.М. Ахунов фотосы*



**36. Радлов Василий Васильевич (1837–1918), российский востоковед-тюрколог, этнограф, археолог и педагог**

**36. Василий Васильевич Радлов (1837–1918) – төрки телләр белгече, этнограф, археолог һәм мөгаллим**

**37. Евфимий Александрович Малов (1835–1918) – миссионер, заслуженный профессор Казанской духовной академии**

*Из личного архива А.М. Ахунова*

**37. Евфимий Александрович Малов (1835–1918) – миссионер, Казан духовной академиясе профессоры**

*А.М. Ахуновның шәхси архивыннан*





38. Татарская учительская школа. Начало XX в.

38. Татар укытучылар мәктәбе. XX йөз башы

*Малашевский Г.А. Старая Казань. Фотопортрет. Книга-альбом. Казань, 2005*



بسم الله الرحمن الرحيم

39. Речь Марджани на открытии Татарской учительской школы. Автограф. Национальная библиотека РТ

*Фото А.М. Ахунова с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.)*

39. Мәрҗанинең Татар укытучылар мәктәбен тантаналы ачу вакытындагы чыгышы. ТР Милли китапханәсе

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсеннән А.М. Ахунов фотосы (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел)*



МИНИСТЕРСТВО НАРОДНАГО ПРОСВѢЩЕНІЯ.

КАЗАНСКІЙ УЧЕБНЫЙ ОКРУГЪ.

40. Представление инспектора татарских, башкирских и киргизских школ В.В. Радлова попечителю Казанского учебного округа П.Д. Шестакову об определении Ш. Богаутдинова (Ш. Марджани) учителем магометанского вероучения в Казанскую татарскую учительскую школу. 1 марта 1876 г.

40. Татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре инспекторы В.В. Радловның Ш. Мәрҗанине Казан укытучылар мәктәбенә мөселман дин укытучысы итеп билгеләү хакында Казан уку-укыту округы попечителе П.Д. Шестаковка гаризасы. 1876 елның 1 марты

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*



41. Группа учеников Татарской учительской школы. Казань. 1894 г.

41. Татар укытучылар мәктәбе укучылары төркеме. Казан. 1894 ел

*Малашевский Г.А. Старая Казань. Фотопортрет. Книга-альбом. Казань, 2005*



Министерство народнаго просвещения

Департаментъ



ДѢЛО

КАНЦЕЛЯРІИ ПОПЕЧИТЕЛЯ КАЗАНСКАГО УЧЕБНАГО ОКРУГА.

42. Отношение управляющего Министерством народного просвещения князя П.А. Ширинского-Шахматова управляющему Казанским учебным округом И.М. Николичу о разрешении приглашать преподавателя магометанского вероучения в Казанской татарской учительской школе на заседание педагогического Совета школы. 11 июня 1876 г.

42. Милли белем бирү Министрлыгы управляющие кенәз П.А. Ширинский-Шахматовның Казан укытучылар мәктәбенең исламият укытучысын Мәктәп советының педагогик утырышына чакырырга ризалык алу турында Казан уку-укыту округы управляющие И.М. Николаевка гаризасы. 1876 елның 11 июне

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*

43. Дело об увольнении преподавателя магометанского вероучения в Казанской татарской учительской школе Ш. Богаутдинова (Ш. Марджани). 24 апреля – 24 июля 1884 г.

43. Казан укытучылар мәктәбенең исламият укытучысы Ш. Мәрҗанине эшеннән азат итү хакындагы эш. 1884 елның 24 апреле

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*


ТРУДЫ

ЧЕТВЕРТАГО АРХЕОЛОГИЧЕСКАГО СЪЕЗДА ВЪ РОССІИ,

бывшаго въ Казани съ 31 іюля по 18 августа 1877 года.

ТОМЪ ПЕРВЫЙ.

КАЗАНЬ.
Типографія Императорскаго Университета.
1884.

**44. Титульный лист «Трудов IV Всероссийского археологического съезда». 1877 г.**

**44. «Труды IV Всероссийского археологического съезда» җыентыгының титул бите. 1877 ел**


القسم الأول من كتاب مستفاد الأخبار
في أحوال قزان وبلغار


بسم الله الرحمن الرحيم

**45. «Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар» («Сведения, привлеченные для истории Казани и Булгара», I – 1885, 1895; II –1900)**

**45. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр», I –1885, 1895; II –1900)**

*https://darul-kutub.com*



**46. Татарский ученый Хусаин Фаизханов (1823–1866)**

**46. Татар галиме Хөсәен Фәезханов (1823–1866)**

*Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: историко-документальный сборник / пер. со старотат. А.М. Ахунова и И.Ф. Гимадеева. Н. Новгород, 2008*



48. **Иосиф Фёдорович Готвальд (1813–1897), известный казанский ориенталист, профессор арабского и персидского языков**

48. **Иосиф Фёдорович Готвальд (1813–1897), танылган Казан ориенталисты, гарәп һәм фарсы телләре буенча профессор**

*Катанов Н.Ф. Императорского Казанского университета почетный член, профессор и библиотекарь И. Ф. Готвальд. Казань: типо-лит. Имп. ун-та, 1900*



47. **Известный татарский ученый и религиозный деятель Риза Фахретдин (1859–1936). Издатель переписки Х. Фаезханова и Ш. Марджани**

47. **Танылган татар галиме һәм дин билгече Риза Фәхретдин (1859–1936). Ш. Мәрҗани һәм Х. Фәезханов хатларын нәшер итүче**

*Нерасторжимая связь: письма Хусаина Фаизханова Ш. Марджани. Москва: ИД «Медина», 2018*



49. **Профессор персидской и турецко-татарской словесности А.Н. Казем-бек (1802–1870).**

*Из личного архива А.М. Ахунова*

49. **Фарсы һәм төрек-татар телләре профессоры А.Н. Казембәк (1802–1870).**

*А.М. Ахуновның шәхси архивыннан*



50. **Альфред Эдмунд Брем (1829–1884) – немецкий учёный-зоолог и путешественник, автор знаменитой научно-популярной работы «Жизнь животных»**

50. **Альфред Эдмунд Брем (1829–1884) – немец зоолог-галиме, сәяхәтче, «Хайваннар тормышы» фәнни-популяр хезмәте авторы**

*Wikimedia Commons*



**51. «Марджани в Казани». Художник А.К. Сайфутдинов (2018)**

*Экспозиция выставки «Ш. Марджани. Татарский характер» (14.09–28.10.2018. г. Казань)*

**51. «Мәрҗани Казанда». Рәссамы А.К. Сәйфетдинов (2018)**

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» экспозициясе (Казан шәһәре. 14.09–28.10.2018 ел)*



**52. Феска Марджани. Музей гимназии № 2 им. Ш. Марджани (г. Казань)**

*Фото А.М. Ахунова с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.)*

**52. Мәрҗанинең фәсе. Казан шәһәренең Ш. Мәрҗани исем. 2 нче номерлы гимназиясе музее**

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсеннән А.М. Ахунов фотосы (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел)*





**53. Мекка. 1889 г.**

**53. Мәккә шәһәре, 1889 ел**

*https://towardsenlightment.wordpress.com*

**54. Фрагмент письма Ш. Марджани из хаджа**

*Фото И.Г. Гумерова с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.)*

**54. Ш. Мәрҗани хаҗ сәфәре вакытында язган хатның фрагменты**

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсеннән И.Г. Гомәров фотосы (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел)*



МИНИСТЕРСТВО
НАРОДНАГО ПРОСВѢЩЕНІЯ
КАЗАНСКІЙ
Учебный Округъ
ИНСПЕКТОРА
КАЗАНСКОЙ ТАТАРСКОЙ УЧИТЕЛЬСКОЙ ШКОЛЫ



**55. Представление заведующего Казанской татарской учительской школой В.В. Радлова попечителю Казанского учебного округа П.Д. Шестакову об увольнении преподавателя вероучения Ш. Богаутдинова (Ш. Марджани) в отпуск в Мекку. 16 июля 1880 г.**

**55. Казан укытучылар мәктәбе җитәкчесе В.В. Радловның исламият укытучысы Ш. Мәрҗанине Мәккә шәһәренә хаҗ сәфәре кылу өчен ялга җибәрү турында Казан уку-укыту округының попечителе П.Д. Шестаковка гаризасы. 1880 елның 16 июле**

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*



**56. Столовые приборы, которыми Ш. Марджани пользовался во время паломничества в хадж**

*Музей Марджани с. Коморгузя. Фото И.Г. Гумерова с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09–28.10.2018 г.)*

**56. Ш. Мәрҗани хаҗ сәфәре вакытында файдаланган савыт-саба**

*Комыргуҗа авылының Мәрҗани музее. «Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсеннән И.Г. Гомәров фотосы (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел)*





**57. Образцы почерков Ш. Марджани. 1) Заявление Ш. Марджани в Духовное управление об издании Корана в г. Казани (1865 г.); 2) Выписки из метрической справки Муртазы Юнусова Муртази. Рукопись, заверена именное печатью Ш. Марджани.**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22. Оп. 1. Ед. хр. 16, 18*

**57. Ш. Мәрҗанинең үз кулы белән язган үрнәкләр: 1) Казан шәһәрендә Коръәнне бастыру хакында Диния нәзарәтенә Ш. Мәрҗани язган гариза (1865 ел); 2) Мортаза Юнысов Мортазинның метрик белешмәсе өземтәсе. Кулъязма Мәрҗанинең шәхси мөһере белән расланган**

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 22. Тасв. 1. С.б. 16, 18*



**58. Метрическая запись по Старокаменной №1 мечети г. Казани о смерти Ш. Богаутдинова (Ш. Марджани). 15 апреля 1889 г.**

**59. Казан шәһәренең Беренче Иске-Таш мәчетендәге Ш. Мәрҗани үлеме хакында метрик язу. 1889 елның 15 апреле.**

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*



**59. Могила Ш. Марджани. Казань, 1978 г. Фотограф Г.В. Юсупов**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22. Оп. 1. Ед. хр. 22*

**59. Ш. Мәрҗани кабере. Казан шәһәре, 1978 ел. Һ.В. Йосыпов фотосы**

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге Ф. 22. Тасв. 1. С.б. 22*



**60. Могила тестя Ш. Марджани Габденнасыра бин Мухамматамина (1919). Мусульманское кладбище г. Буинска**

*Фотограф В.М. Усманов*

**60. Ш. Мәрҗани хатынының әтисе Габденнасыйр бине Мөхәммәтәмин кабере (1919). Буа шәһәренең мөселман зираты**

*В.М. Усманов фотосы*


مرجانی



**61. Сборник «Марджани» по случаю 100-летнего юбилея Ш. Марджани, подготовленный Г. Губайдуллиным и Ш. Шарафом, 1915 г.**

*Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 22. Оп. 1. Ед. хр. 23*

**61. Ш. Мәрҗанинең тууына 100 ел тулуга багышлап Г. Гобәйдуллин һәм Ш. Шәрәф тарафыннан әзерләнгән «Мәрҗани» җыентыгы, 1915 ел**

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 22. Тасв. 1. С.б. 23*



**62. Редколлегия сборника «Марджани». Сидят (слева направо): Кашаф Тарджемани, Салих Губайдуллин, Шахар Шараф, Габдрахман Гумари. Стоят: Габдулла Гисмати, Газиз Губайдуллин, Тагир Ильяси (Казань, 1915 г.)**

**62. «Мәрҗани» җыентыгын төзүчеләр редколлегиясе. Утырганнар (сулдан уңга): Кәшшафетдин Тәрҗемани, Салих Гобәйдуллин, Шәһәр Шәрәф, Габдеррәхман Гомәри. Басканнар: Габдулла Гыйсмәти, Газиз Гобәйдуллин, Таһир Ильяси (Казан, 1915 ел)**

**63. Родственники Ш. Марджани: Ильясова Назия-ханум, Мустафина Суфия-ханум (в центре) вместе с представителями Духовного управления мусульман Татарстана на татарском кладбище (г. Казань, 1998 г.)**

**63. Ш. Мәрҗани туганнары: Ильясова Наҗия ханым белән Мостафина Суфия ханым (уртада) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре белән татар зиратында (Казан, 1998 ел)**

*http://www.archive.gov.tatarstan.ru*







**64. Могила Ш. Марджани на Татарском кладбище Ново-татарской слободы г. Казани. Современный вид. 2018 г.**

*Фотограф А.М. Ахунов*

**64. Казан шәһәренең Яңа Татар бистәсенең татар зиратында Ш. Мәрҗани кабере. Хәзерге күренеше. 2018 ел**

*Ахунов А.М. фотосы.*



65. Двор на улице Комсомольская с видом на мечеть «Марджани» (1930–1940-е гг.)

65. Комсомол урамында урнашкан йорт ишек алдыннан «Мәрҗани» мәчетеннең күренеше. (1930–1940 еллар)

*https://pastvu.com*





66. Улица Каюма Насыри. Вид на мечеть «Марджани» (Казань, 1978 г.). Фотограф Н.Х. Халит

66. Каюм Насыйри урамы. «Мәрҗани» мәчетенең күренеше (Казан, 1978 ел). Н.Х. Халит фотосы

*https://pastvu.com*

67. Старики возвращаются с молитвы из мечети «Марджани» (Казань, 1981 г.). Фотограф Н.Х. Халит

67. Картлар «Мәрҗани» мәчетеннән намаздан кайтып киләләр (Казан, 1981 ел). Н.Х. Халит фотосы

*https://pastvu.com*

**68. «Святой источник». Художник Р.М. Саляхов**

*Фото Гумерова И. Г. с выставки «Шигабутдин Марджани. Татарский характер» (Казанский Кремль. 14.09-28.10.2018 г.)*

**68. «Изге чишмә». Рәссамы Р.М. Сәлахов**

*«Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсеннән Гомәров И.Г. фотосы (Казан Кремле. 14.09–28.10.2018 ел)*





**69. Ш. Марджани. Серия скульптурных портретов «Великие деятели татарской культуры» (Национальная библиотека РТ, 1993–94гг.). Скульптор Ф.Н. Фасхутдинов**

*Фотограф А.М. Ахунов*

**69. Ш. Мәрҗани. «Татар мәдәниятенең бөек эшлеклеләре» сынлы портретлар сериясеннән (ТР Милли китапханәсе, 1993–1994 еллар). Скульторы Ф.Н. Фәсхетдинов**

*А.М. Ахунов фотосы*



**70. Памятный знак в с. Ташкичу Арского р-на РТ**

*Фотограф И.Г. Гумеров*

**70. Татарстан Республикасы Арча районы Ташкичү авылында куелган һәйкәл**

*И.Г. Гомәров фотосы*





**71. «Родник Марджани» (с. Ташкичу). Комплекс был открыт 8 декабря 2017 г.**

*Фотограф И.Г. Гумеров*

**71. «Мәрҗани чишмәсе» (Ташкичү авылы). Комплекс 2017 елның 8 декабрендә ачылган.**

*И.Г. Гомәров фотосы*



**72. Выставка «Шигабутдин Марджани. Татарский характер», посвященная 200-летнему юбилею ученого. Выставочный центр «Манеж» Музея-заповедника «Казанский Кремль» 14 сентября– 28 октября 2018 г.**

*Фотограф А.М. Ахунов*

**72. Галимнең тууына 200-ел тулуга багышланган «Шиһабетдин Мәрҗани. Татар характеры» күргәзмәсе. «Манеж» күргәзмә үзәге. Казан Кремле музей-тыюлыгы. 2018 елның 14 сентябре – 28 октябре**

*А.М. Ахунов фотосы*



**73. «Марджани».**
**Художник Р.И. Шамсутов**

*Музей Марджани с. Коморгузя (Атнинский р-н, Респ. Татарстан)*

**«Мәрҗани».**
**Рәссамы Р.И. Шәмсутов**

*Коморгуҗа авылындагы Мәрҗани музее (ТР, Әтнә районы)*



**74. Сборник хадисов XIV в. «Сахих ал-Бухари» из личной библиотеки Ш. Марджани. Из фондов Музея-заповедника «Казанский Кремль»**

*Фотограф А.М. Ахунов*

**74. Ш. Мәрҗанинең шәхси архивында сакланган «Сахих әл Бохари» хәдисләр җыентыгы (XIV гасыр). «Казан Кремле» музей-тыюлыгы фондыннан**

*А.М. Ахунов фотосы*



**75. Страницы рукописей Марджани. Российская национальная библиотека и Институт восточных рукописей РАН (Санкт-Петербург), автографы ученого из коллекций Научной библиотеки К(П)ФУ, Института языка, литературы, искусства АН РТ, Национальной библиотеки РТ**

*Фотограф А.М. Ахунов*

**75. Мәрҗанинең кулъязмалары. Россия милли китапханәсе. Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кулъязмалар институты (Санкт-Петербург). Галимнең КФУ фәнни китапханәсе, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТР Милли китапханәсендә саклanучы автографлары**

*А.М. Ахунов фотосы*



**76. В ноябре 2018 г., в честь 200-летия со дня рождения учёного в Казани был открыт памятник Ш. Марджани**

*Фотограф А.М. Ахунов*

**76. Галимнең тууына 200 ел тулуга багышлап 2018 елның ноябрендә Казанда Ш. Мәрҗәни һәйкәле ачылды**

*А.М. Ахунов фотосы*

МАРДЖАНИ и его эпоха в фотографиях

Ахунов Азат Марсович
**МАРДЖАНИ И ЕГО ЭПОХА В ФОТОГРАФИЯХ**

Перевод на татарский язык *А.К. Булатовой*
Перевод на английский язык *Ч.И. Хамидовой*

Дизайн *А.В. Булатова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Формат 84×90 1/16. Гарнитура «Cambria».
Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 5,95. Уч.-изд. л. 4. Тираж 500 экз. Заказ

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20